# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Камышлы-Күл торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**18.03.2024 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге башлыгының 07.03.2024 елгы 1 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Камышлы-Күл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 02.12.2023 елгы 1 номерлы, “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Камышлы-Күл торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” 02.12.2023 елгы 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең Камышлы-Күл торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Камышлы-Күл авылы гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең Камышлы-Күл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 02.12.2023 елгы № 1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең Камышлы-Күл торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 02.12.2023 елгы № 2 гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Камышлы-Күл авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны кардан чистарту, тракторчыга карны механикалаштырылган җыештыру буенча хезмәтләр өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре, килешү буенча эш өчен түләү))

2) Камышлы-Күл торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (энергия саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)»

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Туйкә авыл җирлеге мәгълүмати стендында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru),Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Закирова